СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.07.2026 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 9-53

с. Кильдеево

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советының 29.03.2013 ел № 30 – 159 карары белән (26.05.2021 ел № 8 – 52 карары үзгәрешләре белән),

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге Советы
карар итте

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә, «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 19 нчеы филиалы Уланово авыл клубын бетерү мәсьәләсе буенча халык фикерен ачыклау максатында, исемле тавыш бирү рәвешендә гражданнардан сораштыру үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- сораштыруны үткәрү датасы һәм вакыты - 07.08.2026 ел 8.00 дән 20.00 гә кадәр;

- сораштыру үткәрү урыны – Килди авылы мәдәният йорты бинасы (адресы:

Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Килди авылы, Үзәк ур., 16А йорт), Уланово авылы клубы бинасы (адресы: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Уланово авылы, Заозерная ур., 44 йорт, Харино авылы, Федяево авылы) – халыкны теркәү урынын карап чыгу.

3. Сораштыру исемлекләре буенча исемләп тавыш бирү үткәрергә

4. Гражданнардан сораштыру үткәргәндә сораштыру исемлегенә кертү өчен түбәндәге сорауның формулировкасын расларга: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 19 нчы филиалы Уланово авыл клубын бетерүгә ризамы?"

5. Сораштыру үткәрү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).

6. Сораштыру исемлегенең формасын һәм текстын расларга (2 нче кушымта).

7. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә 1780 кешедән торган сораштыруда катнашучыларның минималь санын билгеләргә.

8. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге башлыгы В.М.Бурдин

Татарстан Республикасы

Югары Ослан муниципаль районы

Килди авыл җирлеге Советының

27.07.2026 ел, №9-53 карарына

1 нче кушымта

Гражданнардан сораштыру үткәрү

КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

1.Бурдин Виктор Михайлович – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башлыгы

2.Лёвочкина Наталья Николаевна – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре
3.Сальнова Ольга Николаевна – Килди авылында яшәүче

4.Мукаева Роза Александровна – Килди авылында яшәүче

5.Лазарева Людмила Анатольевна – Килди авылында яшәүче

6.Романова Валентина Ивановна – 2 нче Килди сайлау округы буенча Килди авыл җирлеге Советы депутаты

Татарстан Республикасы

Югары Ослан муниципаль районы

Килди авыл җирлеге Советының

27.07.2026 ел, №9-53 карарына

2нче кушымта

СОРАШТЫРУ ИСЕМЛЕГЕ

Сораштыру үткәрелә торган сорауны формулировкалау: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 19 нчы филиалы Уланово авыл клубын бетерүгә ризамы?"

| Фамилия, исеме, атасы исеме | Туган көне, ае һәм елы | Яшәү урынының адресы | Дата | Тавыш бирү тамгасы | | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | РИЗА | КАРШЫ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |

Комиссия рәисе

______________________________________________________________

(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)

Комиссия секретаре

____________________ ______________________________________

(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)